ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында» 72-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында» 72-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 260-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Л.А. Якунин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IVөлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гынварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Татарстан Республикасында 2019 елның 1 гыйнварыннан «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимы кертелде.

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән һөнәри керемгә салымнан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле шәһәр, авыл җирлекләре һәм шәһәр округлары бюджетларына керемнәр түләү 100 процент норматив белән билгеләнде.

Физик затларның салым органнары белән үзара хезмәттәшлеге (салым суммасын исәпкә кую, исәпләү һәм түләү, исәптән төшерү һ.б.) «Минем салым» мобиль кушымтасы аша гамәлгә ашырыла.

«Минем салым» мобиль кушымтасының техник мөмкинлеге һөнәри керемгә салымны җирле бюджетларга түләүне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы бюджеты югалтуларын булдырмау һәм керә торган һөнәри керемгә салым суммаларын «ачыкланмаган» категориясенә кертүне булдырмау өчен Татарстан Республикасы Бюджет кодексының шәһәр, авыл җирлекләре һәм шәһәр округлары бюджетларына керә торган салым суммаларын түләү турындагы нормасының гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварына кадәр туктатылды.

Әлеге кушымтаны федераль дәрәҗәдә эшләп бетерү планлаштырылмавын исәпкә алып, закон проекты белән шәһәр, авыл җирлекләре һәм шәһәр округлары бюджетларына салым суммаларын күчерү турында Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нормасының үз көчен югалтуын тану тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

Закон проекты белән һөнәри керемгә салымнан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле шәһәр, авыл җирлекләренең һәм шәһәр округларының бюджетларына салым керемнәре түләү нормативын билгели торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының үз көчен югалтуы танылa.

Законны кабул итү Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетының керем һәм салым өлешләренә тәэсир ясамаячак.